Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № № XIII-7**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 16 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2007 елның 4 октябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау ведомствоара комиссиясе турында” XIX-8 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында” 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2007 елның 4 октябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау ведомствоара комиссиясе турында” XIX-8 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев